Дәүләт автоном һөнәри белем бирүче
“Мамадыш политехник көллияте” мәгариф учреждениесе
(ДАҺБУ “Мамадыш ПК»)

РАСЛЫЙМ
ТУ буенча директор урынбасары
_________ Фәйзреева В.В.
«25» август 2020 ел

ППКРС 43.01.09 Пешекче, кондитер

# ОУД.12 ТУГАН ТЕЛ

# УКЫТУ ФӘНЕНЕҢ ЭШ ПРОГРАММАСЫ

2020 ел

Укыту фәненең эш программасы: «Эшче кадрлар әзерләү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең департаменты тарафыннан тәкъдим ителгән төп гомуми белем бирү стандартлары таләпләрен исәпкә алып, төп гомуми белем базасында урта һөнәри белем бирү уку программаларын үзләштерү чикләрендә урта гомуми белем алуны оештыру буенча тәкъдимнәр» нигезендә төзелгән һәм өстәмә һөнәри белем бирү министрлыгының һәм фән Россия Федерациясе, Департамент директоры хаты Н.М. Золотаревага 2015 елның 17 мартындагы 06-259 номерлы; «Мәгариф үсеше федераль институты» федераль дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан тәкъдим ителгән «Гомуми белем бирү укыту дисциплинасының якынча программасы» (2015 елның 21 июлендәге 3 нче беркетмә) нигезендә төзелгән:

Цикллы методик комиссия утырышында фикер алышынды һәм хупланды

Эшкәртүче:

гомумгуманитар һәм социаль-икътисадый дисциплиналарның циклы
ЦМК исеме

_________/А.Д. Әхмәтшина
имза, инициаллар фамилиясе

Протокол №1

«26» август 2020 ел

Зав. ПЦК ________/ Л.В. Ямалиева
Подпись, инициалы фамилия

**ЭЧТӘЛЕК**

**УКУ ФӘНЕНЕҢ ЭШ ПРОГРАММАСЫ ПАСПОРТЫ.............................4**

**УКУ ФӘНЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ.........................................................................7**

**УКУ ФӘНЕН ТОРМЫШКА АШЫРУ ШАРТЛАРЫ............................. 16**

**УКУ ФӘНЕН ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ТИКШЕРҮ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ............... 18**

## Уку фәненең эш программасы паспорты:

**Туган тел фәне**

Белгечлек төре: 43.01.09. – Пешекче, кондитер

**Фән төзелеше:**

Һөнәри белем бирүче “Мамадыш политехник көллияте” дәүләт автономияле мәгариф учреждениесендә татар теле һәм әдәбиятын укыту программасы 3 бүлектән тора: эш программасының паспорты, төп эчтәлек, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр.

**Фәннең гомуми характеристикасы:**

Программа Татарстан республикасында һөнәр көллиятендә тулы булмаган урта мәктәп белемле татар балаларына татар телен укыту өчен төзелде. Көллияттә татар теленә гуманитар предметлар рәтеннән беренче дәрәҗәдәге әһәмият бирелә, ул ана телендә укытыла торган башка фәннәрне өйрәнү теле дә, укучыларның рухи дөньясын, әхлагын формалаштыруда әһәмиятле чара да. Ана теле ярдәмендә укучылар буыннар тәҗрибәсе белән тупланган мәдәният һәм сәнгать кыйммәтләре белән таныша, алардагы уңай сыйфатларны үзләштерә, укучыда туган җиренә мәхәббәт хисе тәрбияләнә.

Тел дәресләрендә, сүз сәнгате буларак, җөмләләрне аңлау һәм кабул итү дәрәҗәсе камилләшә. Татар теле дәресләрендә рус телен, чит ил телләрен өйрәнүгә дә нигез салына. Татар теле дәресләрендә танып белү, фикерләү сәләтен үстерүгә зур игътибар бирелә. Укучыларның акыл һәм иҗади сәләтләрен үстерү тәэмин ителә, хәтерләре һәм күзаллау дәрәҗәсе яхшыра, гомуми караш даирәсе үстерелә, мөстәкыйль уку эшчәнлеге күнекмәләре формалаша. Төрле белемнәрне үзләштерү һәм саклау формасы буларак, татар теле көллияттә укытыла торган башка предметлар белән тыгыз бәйләнештә тора һәм аларны үзләштерү сыйфатына уңай тәэсир итә.

Пешекчеләрнең матур һәм дөрес итеп ике телдә сөйләшә белүләре ашау ризыклары атамаларын белергә, кешеләр белән аралашканда бик кирәк.

**Фәннең максаты һәм бурычлары:**

Дәресләрдә бирелә торган белем, осталык һәм күнекмәләрнең күләме җәмгыятебезнең иҗтимагый функцияләренә туры китереп билгеләнә. Төп идеясе - укытуның фәнни һәм гамәли нигездә оештырылуы, телне тирәнтен белү, туган тел ярдәмендә үзара иркен аңлашу, уй-фикерләреңне һәм хис – тойгыларыңны дөрес һәм төгәл итеп белдер укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, сөйләм һәм язма телен үстерү белән беррәттән, рухи дөньясын баету, реаль чынбарлыкка дөрес караш формалаштыру, тормыш вакыйгаларына хәбәрдарлыгын тәэмин итү; татар теленнән алынган теоретик материалны (тел системасын) аңлап үзләштерүне һәм тел фәнен яхшы белүне тәэмин итү; гамәли тел материалларын хәтердә калдырып һәм тәрбияви максатны күздә тоткан хәлдә, әдәбият дәресләре программасында бирелгән текстларны анализлый белү, изложение һәм сочинениеләрне логик фикерләп, телдәге сурәтләү чараларын дөрес һәм урынлы кулланып, грамоталы итеп һәм дөрес каллиграфия белән яза белүләренә ирешү, идея дәрәҗәсенең югары булуын тәэмин итү, текст өстендә эшләү күнекмәләрен камилләштерү, үзеңнең һәм иптәшләреңнең кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү, информация чыганакларыннан кирәкле мәгълүматларны таба һәм куллана белергә өйрәтү;укучыларда дәреслек һәм өстәмә әдәбияттан (әдәби әсәрләре, фәнни чыганаклар, төрле сүзлекләр, вакытлы матбугат) дөрес файдалану күнекмәләрен үстерү, план, тезис, конспектлар төзү, эш кәгазьләрен (деловые бумаги) дөрес һәм грамоталы язарга өйрәтү; бәйләнешле сөйләм культурасын үстерү өчен, укучыларда укыганны һәм сөйләгәнне кабул итү, сөйләмнән урынлы файдалану осталыгын (уку,язу,сөйләү,тыңлау, аңлау, сөйләшү, аралашу, диалогик һәм монологик сөйләм) иҗади эш башкару күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү.

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

Укучылар үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:

1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү

2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.

3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.

4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълумат алу.

5. Язу тарихын тирән белү.

6. Язучыларның тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксыну.

**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**

1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.

2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.

3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау

4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.

5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.

6. Орфографик принциплар һәм аларның нормаларын белү.

7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.

8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.

9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу.

10. Язучыларның әсәрләрен белү, әсәрләр ярдәмендә тормыш тәҗрибәсен туплау.

11. Якташлар иҗаты белән кызыксыну.

12. Матур әдәбият әсәрләрен укып – сөйләм дәрәҗәсен арттыру.

**Фәнне үзләштерү өчен сәгатьләр саны:**

Максималь уку йөкләнеше: 114 сәгать;

Барлыгы:  114 сәгать;

Теория: 108 сәгать;

Консультацияләр: 4 сәгать;

Промежуточная аттестация (диф. зачет): 2 сәгать;

## Уку программасынның эчтәлеге

| Бүлекләр һәм темалар исемлеге | Укыту материалының эчтәлеге, практик эш, укучыларның үзлектән эше | Үткәрелгән вакыты (сәг.) | Үзләш. дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1нче бүлек** | **Тел – аралашу чарасы, иҗтимагый һәм сәяси күренеш** | **8** | |
| | 1 Тел гыйлеме турында төшенчә. Тел гыйлеменә өйрәтә торган фәннәр.<br>2 Телнең төп функцияләре<br>3 Дөнядагы телләр, аларны төркемләү<br>4 Дөньядагы телләр арасында татар теленең тоткан урыны<br>5 Телдән сөйләм<br>6 Язма сөйләм<br>7 Практик эш: күнегүләр эшләү | 7 | 1<br>2 |
| | **8 Тикшерү эше:** Кереш тикшерүе. №1 Диктант | 1 | 3 |
| **2 бүлек** | **Фонетика.** | **6** | |
| | **9 Хаталар өстендә эш. Авазлар һәм хәрефләр.**<br>**10 Тартык һәм сузык авазлар.**<br>**11 Аваз үзгәрешләре**<br>12 Сингармонизм законы<br>13 Графика, орфография | **6** | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 14 Сүзләргә фонетик- график анализ ясау тәртибе | | 2 |
| **3нче бүлек** | **Лексика** | **7** | |
| | 15 Синонимнар,антонимнар.<br>**16 Күп мәгънәле сүзләр.Фразеология.**<br>**17 Татар теленең сүзлек составы. Омонимнар.** | 3 | 1 |
| | **18** Диктант. | 1 | 3 |
| | 19 Хаталар өстендә эш. Этимология турында төшенчә. Калькалар<br>20 Лексикография | 2 | |
| | **21** "Лексикология" бүлеге буенча контроль эш. | 1 | 3 |
| **4 нче бүлек** | **Морфология** | | |
| | **Исем** | **3** | |
| | 22 Исемнәрнең берлек һәм күплек саны. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше.<br><br>23 Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.Ялгызлык, уртак- лык исемнәр.<br><br>24 Исем сүз төркеменә морфологик анализ | 3 | 1<br><br>2 |
| | | | |
| | **Сыйфат** | **2** | |
| | 25 Сыйфатларның ясалышы . Сыйфат дәрәҗәләре.<br><br>26 Исемләшкән сыйфатлар. Сыйфат сүз төркеменә морфологик анализ. | 2 | 1<br><br>2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | **Сан** | **2** | |
| | 27 Саннарның ясалышы. Сан төркемчәләре.<br>28 Сан сүз төркеменә морфологик анализ. | 2 | 1<br>2 |
| | | | |
| | **Алмашлык** | **2** | |
| | 29 Алмашлыклар.<br>**30** Алмашлык сүз төркеменә морфологик анализ. | 2 | 1<br>2 |
| | **Фигыль** | 9 | |
| | 31 Затланышлы фигыльләр<br>32 Затланышсыз фигыльләр<br>33 Фигыль төркемчәләре, юнәлешләре<br>34 Фигыльләрдә зат-сан категориясе<br>35 Фигыльләрдә заман категориясе. Контроль эш.<br>36 Фигыль дәрәҗәләре<br>37 Фигыльләргә морфологик анализ ясау. | 7 | 1<br>3<br>2 |
| | **38 – 39 Изложение** | 2 | |
| | **Рәвеш** | **3** | |
| | 40 Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре.<br>41 Рәвеш сүз төркеменә морфологик анализ ясау | 2 | 1<br>2 |
| | **42** “Сүз төркемнәре” темасына контроль эш. Тестлар. | 1 | 3 |
| **5 нче бүлек** | **Синтаксис** | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | **Җөмләдә сүзләр бәйләнеше** | **4** | 1<br><br>1<br><br>3 |
| | Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар.<br>Ияртүле бәйләнешне белдерүче чаралар.<br>Сүзтезмә һәм тезмә сүз. | **3** | |
| | **43 Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар.**<br>**44 Ияртүле бәйләнешне белдерүче чаралар.**<br>**45 Сүзтезмә һәм тезмә сүз.** | 3 | |
| | **46 Биремле диктант.** | 1 | |
| **7 нче бүлек** | **Гади жөмлә** | **5** | |
| | **47 Хаталар өстендә эш.** Җөмлә.<br>48 Җөмләнең баш кисәкләре. Ия.<br>49 Җөмләнең баш кисәкләре.Хәбәр.<br>50 Ия белән хәбәрнең ярашуы.<br>51 Ия белән хәбәр арасында сызык кую очраклары. | **5** | 1 |
| **8 нче бүлек** | **Җөмләнең иярчен кисәкләре** | **12** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 52 Җөмләнең иярчен кисәкләре-аергыч<br>53 Җөмләнең иярчен кисәкләре-тәмамлыклар<br>54 Җөмләнең иярчен кисәкләре-вакыт,урын хәлләре<br>55 Җөмләнең иярчен кисәкләре-сәбәп хәле<br>56 Җөмләнең иярчен кисәкләре-максат хәле<br>57 Җөмләнең иярчен кисәкләре- рәвеш хәле<br>58 Җөмләнең иярчен кисәкләре-күләм хәле<br>59 Җөмләнең иярчен кисәкләре-шарт хәле | **11** | 1 |
| | 60 Җөмләнең иярчен кисәкләре-кире хәл<br>61 Аныклагычлар<br>62 Аныклагычлар янында тыныш билгеләре | | |
| | **63** Диктант. | 1 | 3 |
| **9 нчы бүлек** | **Җөмләнең модаль кисәкләре** | **4** | |
| | 64 Хаталар өстендә эш. Кереш сүзләр<br>65 Җөмләнең модаль кисәкләре | 2 | 1 |
| | **66 – 67 И**зложение | 2 | 2 |
| | | | |
| **10 нче бүлек** | **Кушма җөмлә** | **9** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 68 Тезмә кушма җөмләләр<br>69 Иярченле кушма җөмләләр<br>70 Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре.<br>71 Иярчен ия җөмлә .<br>72 Иярчен хәбәр җөмлә.<br>73 Иярчен аергыч җөмлә.<br><br>**74** Контроль эш.<br>75 Хаталар өстендә эш. | 6<br><br><br><br><br>1<br><br>1 | 1<br><br><br><br>3 |
| | **76 Бүлекне йомгаклау тестлары** | **1** | |
| | **Барлыгы:** | **76с. (1курс)** | |

**Уку дисциплинасының эчтәлеге һәм структурасы**
**2 курс**
**Туган тел**

| **Укыту эшләре төре** | **Сәгать саны** |
|---|---|
| **Барлыгы (2 курс)** | **38** |
| **Дәресләрдәге шөгыль** | **38** |
| шул исәптән: | |
| **Йомгаклау аттестациясе – зачет.** | **2** |
| Консультация | **4** |

## Уку программасынның эчтәлеге

| Бүлекләр һәм темалар исемлеге | Укыту материалының эчтәлеге, практик эш, укучыларның үзлектән эше | Үткәрелгән вакыты (сәг.) | Үзләш. дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1нче бүлек** | **Тел – аралашу чарасы, иҗтимагый һәм сәяси күренеш** | **8** | |
| 1 | Тел гыйлеме турында төшенчә. Тел гыйлеменә өйрәтә торган фәннәр. | **1** | |
| 2 | Телнең төп функцияләре | **1** | 1 |
| 3 | Дөньядагы телләр, аларны төркемләү | **1** | |
| 4 | Дөньядагы телләр арасында татар теленең тоткан урыны | **1** | |
| 5 | Телдән сөйләм | **1** | |
| 6 | Язма сөйләм | **1** | |
| 7 | **Практик эш: Күнегүләр эшләү** | **1** | 2 |
| 8 | Кереш тикшерүе: Диктант | **1** | 3 |
| **2 бүлек** | **Фонетика.** | **6** | |
| 9 | Хаталар өстендә эш. Авазлар һәм хәрефләр. | | 1 |
| 10 | Тартык һәм сузык авазлар. | | |
| 11 | Аваз үзгәрешләре. | | |
| 12 | Сингармонизм законы. | | |
| 13 | Графика, орфография. | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14 | Сүзгә фонетик-график анализ ясау тәртибе | | 2 |
| **3нче бүлек** | **Лексика** | **7** | 1 |
| **15** | Синонимнар,антонимнар | | |
| **16** | Күп мәгънәле сүзләр. Фразеология. | | |
| **17** | Татар теленең сүзлек составы. Омонимнар | | 3 |
| **18** | Диктант. | | |
| **19** | Хаталар өстендә эш. Этимология турында төшенчә. | | |
| **20** | Лексикография. | | 3 |
| **21** | “Лексикология” бүлеге буенча контроль эш. | | |
| **4 нче бүлек** | **Морфология** | | |
| | **Исем** | **3** | 1 |
| **22** | Исемнәрнең берлек һәм күплек саны. | | |
| **23** | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | | |
| **24** | Исем сүз төркеменә морфологик анализ. | | |
| | **Сыйфат** | **2** | |
| 25 | Сыйфатларның ясалышы. Сыйфат дәрәҗәләре. | | 1 |
| 26 | Исемләшкән сыйфатлар. Сыйфат сүз төркеме. | | |
| | **Сан** | **2** | |
| 27 | Саннарның ясалышы.  Сан төркемчәләре | | 2 |
| 28 | Сан  сүз төркеменә морфологик анализ. | | |
| | **Алмашлык** | **2** | 2 |
| 29 | Алмашлыклар. | | |
| 30 | Алмашлык сүз төркеменә морфологик анализ | | |
| | **Фигыль** | **2** | 1 |
| 31 | Затланышлы фигыльләр | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 32 | Затланышсыз фигыльләр | | |
| **Консультация:** | | | |
| 33 | Консультация № 1. Фигыль төркемчәләре, юнәлешләре | **4** | |
| 34 | Консультация № 2. Фигыльләрдә зат-сан категориясе | | |
| 35 | Консультация № 3. Фигыльләрдә заман категориясе | | |
| 36 | Консультация № 4. Фигыль дәрәҗәләре. | | |
| 37 | Фигыльләргә морфологик анализ ясау. Зачет. | **2** | |
| 38 | Диф. зачет. | | |
| Программа буенча : **32 с. + 4 консультация + 2 промежуточная аттестация = 38 с. (2 курс)** | | | |
| Барлыгы: 114 с.: 108 с. теория + 4 с. консультация + 2 с. промежуточная аттестация | | | |

**4. Уку фәнен тормышка ашыру  шартлары**

**4.1. Минималь материаль – техник  тәэмин ителешкә таләпләр**

Фән программасы тормышка ашыру кабинет булуны таләп итә: татар теле кабинеты.

Уку кабинетының җаһазлары:  язу тактасы, кием шкафы, китап шкафы, өстәл (укучылар өчен), өстәл  (укытучылар өчен), урындыклар.

**4.2. Белем бирүнең техник чаралары:**

- Интерактив комплект (Инв. № 222101045615);
- Портатив ПЭВМ RAYbook Bi1010 ICL ( Инв. № 222101045648).

**Кулланылган әдәбият**

**Студентлар өчен:**

1. Татар теле: рус телендә  урта гомуми белем бирү мәкт. 11нче с-фы өчен д-лек(татар балалары өчен) Ф.С. Сафиуллина, С.М.Ибраһимов; -Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. – 247 б .

2.Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 10 нчы с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен)  Р.С. Абдуллина, Г.М.Шәйхиева.- Казан: Татар.кит.нәшр., 2017.- 158б

**Укытучылар өчен:**

1. Россия Федерациясе мәгарифе турында” гы федераль закон - ФЗ “Об образовании в Российской Федерации ( 2012 нче елның 29 нчы декабрендә РФ Президенты тарафыннан имзаланган 273 нче ФЗ; 2013 нче елның 1нче сентябреннән гамәлдә) – 26 б.

2.Татарстан Республикасының “Мәгариф турындагы” Законы  (1.09.2013);

3.“2014 -2020 нче елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау һәм өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы” (№794 от 25.10.2013)- 22 б.

4.РФ мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары белән гомуми белем бирүнең өч (башлангыч белем бирү – № 373 06.10.2009ел; төп гомуми белем бирү - №1897, 17.12.2010ел; урта(тулы) гомуми белем бирү - № 413, 17.05.2012ел). - 39 б.

## 5.Фәнне үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү

| **Укыту нәтиҗәсе<br>( белергә, эшләргә тиеш)** | **Уку нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү формалары һәм алымнары** |
|---|---|
| **Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:**<br>1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү.<br>2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.<br>3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.<br>4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу.<br>5. Язу тарихын тирән белү.<br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**<br>1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.<br>2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.<br>3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау<br>4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.<br>5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.<br>6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.<br>7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.<br>8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.<br>9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу. | Изложение; диктант; тестлар; реферат; сорауларга җавап бирү; күнегүләр эшләү; конспектлар төзү. |